**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы №31 «20» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка Советының 12 август 2014 елның 97 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка муниципаль хезмәт турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында (12.11.2015 №14, от 13.12.2016 №46, от 23.04.2019 №129, от 03.02.2020 №160, от 24.02.2021 №2, от 23.09.2021 №15, от 18.04.2023 №15 номерлы карарлар редакциясендэ)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка Уставы нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Советының 12 август 2014 елның 97 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында 12.11.2015 №14, от 13.12.2016 №46, от 23.04.2019 №129, от 03.02.2020 №160, от 24.02.2021 №2, от 23.09.2021 №15, от 18.04.2023 №15 карарлар редакциясендә) карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче бүлектә:

2 пунктта «, муниципаль җирлекнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4. “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка муниципаль хезмәте Россия Федерациясе Конституциясе белән, Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы (авыл җирлеге исеме) Уставы, әлеге Нигезләмә һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 пунктта “Муниципаль хезмәт турында» Федераль законы» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон сүзләренә алмаштырырга, «2013 елның 25 июнендәге №50-ТРЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 бүлекнең 4 пунктында «2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 4.1 бүлектә:

1 пунктта:

4 пунктчада «Муниципаль хезмәт турында» Федераль законы» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законы” сүзләренә алмаштырырга.

9 пунктчада «Муниципаль хезмәт турында» Федераль законы» сүзләрен Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законы” сүзләренә алмаштырырга.

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4.2 бүлекнең 1 пунктында:

1 пунктчаның дүртенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада:

икенче абзацта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җирле үзидарә органында ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән яисә федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган өченче зат эшләре буенча вәкил булырга;»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) вазыйфаи торышына бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләр (акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләү) алырга. Беркетмә чараларына бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә алынган бүләкләр хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән, муниципаль

милек дип танылa һәм, Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына акт буенча муниципаль хезмәткәрләргә тапшырыла. Беркетмә чарасына бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр хезмәт командировкасы яисә башка рәсми чара белән, аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;»;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) үзара башкарыла торган командировкалардан тыш җирле үзидарә органының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, шулай ук чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит ил коммерциягә карамаган оешмалары белән килешүләре буенча физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән командировкаларга чыгарга;»;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) массакүләм мәгълүмат чараларында, җирле үзидарә органы һәм аның җитәкчесе эшчәнлегенә карата, әгәр бу аның вазыйфаи бурычларына кермәсә гавами әйтелмәләр, фикер йөртүләр һәм бәяләүләр рөхсәт ителә ;»;

5) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә җирлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә»;

6) 6 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Җирлекнең муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан уздырыла.

7) 9.2 бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Муниципаль хезмәткәрләргә чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә әлеге Нигезләмәнең 9.2 бүлегендә каралган түләүләр салына.»;

3 пунктның 1 пунктчасында " яисә 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Россия Федерациясе Президенты Хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан" сүзләрен өстәргә;

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Советының 12 август 2014 елның 97 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт

турында 12.11.2015 №14, от 13.12.2016 №46, от 23.04.2019 №129, от 03.02.2020 №160, от 24.02.2021 №2, от 23.09.2021 №15, от 18.04.2023 №15 карарлар редакциясендә)» карарының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе»нең 2 нче кушымтасының 7 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Рәис каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Г.Солтанова